**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Карамалинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советы башлыгы**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы,
Азнакаевского муниципального района, 423301
Тел. (факс) (8-5) 45-6-42

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «09» ноябрь 2020 ел №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Карамалы авыл җирлеге
Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның «20» ноябреньдә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2020 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өчен: 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәкләр, күп балалы гаиләләр, өчен түләү күләмен 50 (илле) процентка киметеп, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Таллы-Бүләк торак пунктында Урман урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Таллы-Бүләк торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Таллы-Бүләк торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Таллы-Бүләк - торак пунктында зиратларына койма кую өчен төзелеш материаллары сатып алу, зиратларны коймалап алу һәм урнаштыру, лак-буяу материалы сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

Азнакай районы, Карамалы авылы, Яшьләр ур., 3 нче йорт;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайты Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Р. Ногманов

КАРАМАЛЫ
АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ
СОВЕТ
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ